**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «8» апреленнән № 20-165

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 апрелендәге 33-191 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2014 елның 11 апрелендәге 33-191 номерлы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Конкурста катнашу өчен сайлап алу процедурасында катнашырга теләк белдергән дәгъвачылар Комиссиягә түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

1. шәхси гариза;
2. әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм фотосурәтле анкета;
3. паспорт күчермәсе;
4. хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;
5. белем алу турындагы документ күчермәсе;
6. муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткә кергән ел алдыннан өч календарь ел эчендә хезмәткә кергәндә, муниципаль хезмәткәр һәркем өчен мөмкин булган мәгълүмат урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар һәм (яки) сайтларның адреслары

турында белешмәләр, шулай ук аларны билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматларны эшкә алучы вәкиленә тапшыралар.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Яңа Чишмәhttp://pravo.tatarstan.ru муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов